**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Азнакай шәһәре Советы дүртенче чакырылыш**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 197-37 «25» ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында"гы карар проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарындагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Азнакай шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Азнакай шәһәре Советы карар кабул итте:

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проектын) кабул итәргә (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo.tatar.ru һәм 2024 елның 29 ноябреннән дә соңга калмыйча «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) Бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырырга.

3. Азнакай шәһәре Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проекты буенча 2024 елның 27 декабрендә 17.00 сәгатьтә түбәндәге адрес буенча гавами тыңлауларны үткәрергә: Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт.

4. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проекты буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча тапшырылырга мөмкин: Азнакай шәһәре, Ленин урамы, 22 йорт, каб. 11.

5. Гавами тыңлауларгы үткәрү буенча түбәндәге составта эшче төркемне төзергә:

- Габдрахманов Эльвир Әнвәр улы-Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе;

– Сабирҗанов Наил Галиәсгар улы-Азнакай районы Советы авыл җирлекләре белән эшләү бүлеге мөдире;

- Хәмидуллина Лилия Фалинур кызы - Азнакай районы Советы авыл җирлекләре белән эшләү бүлеге баш белгече;

- Галиева Эльвира Сәйлүн кызы-Азнакай район Советының оештыру бүлеге җитәкчесе.

6. Гавами тыңлауларны уздыру буенча эшче төркемгә «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы карар проекты буенча гавами

тыңлауларны уздыруны, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә, фикер алышу барышында кергән гавами тыңлауларда әйтелгән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М.З.Шәйдуллин

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2024 елның 25 ноябрендәге 197-37 номерлы карарына №1 кушымта

1. Татарстан Республикасы Азнакай шәһәре Советының 2012 елның 15 мартындагы 58-17 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына (06.12.2012 №82-23, 22.10.2013 №108-31, 12.08.2014 №138-40, 17.03.2016 №18-5, 02.02.2017 №43-13, 30.03.2018 №85-24, 22.08.2018 №105-27, 22.10.2019 №148-36, 22.10.2020 №10-2, 26.10.2021 №52-11, 12.10.2022 №94-18, 19.02.2024 №169-29 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

.1. 6 статьяда:

а) 1 өлешнең 31 пунктчасында «җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук " сүзләрен төшереп калдырырга.;

б) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 45 пунктчаны өстәргә:

"45) "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында"гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

1.2. 29 статьяда:

а) 7 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)»сүзләренә алмаштырырга.;

б) 8 өлештә «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)»сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 39 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктчасы өстәргә::

"10.1) аның чит ил агенты статусын алуы;".

1.4. 47 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле алты абзац өстәргә::

- "Шәхси ярдәмче хуҗалык турында"гы 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә ала.»;

б) 1 өлешнең 3 пунктындагы 9 абзацында «җирлек территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыра, үстерә һәм саклауны тәэмин итә, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Дәүләт теркәвеннән соң, әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» http://aznakaevo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча Азнакай шәһәре Советының даими комиссиясенә йөкләргә.